
# Иярченле  җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре



* Баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз кайсы кисәк булып килсә, аның ярдәмендә бәйләнгән иярчен җөмлә шул ук кисәккә туры килә торган иярчен җөмлә була.

Иярчен ия җөмлә баш җөмләнең иясе урынында килә һәм кем? нәрсә? сорауларына җавап була

Мәсәлән, Кем намус белән хезмәт итә, шул зур хөрмәткә ия була.

Иярчен хәбәр җөмлә  баш җөмләнең хәбәре урынында килә һәм нинди? нәрсә? нәрсәдән? кемгә? күпме? кебек сорауларга җавап бирә.

Мәсәлән, Ул йомыш шул:без сине Кырымга җибәрмәкче булабыз.

Иярчен тәмамлык җөмлә баш җөмләнең тәмамлыгы урынында килә һәм кемне? нәрсәне? кемгә? нәрсәгә? кемнән? нәрсәдән? кемдә? нәрсәдә? кебек сорауларга җавап бирә.

Мәсәлән, Үзегез күрәсез: бер тамчы яңгыр яуганы юк.

Иярчен аергыч җөмлә баш җәмләнең аергычы урынында килә һәм нинди? кайсы? кемнең? кебек? сорауларга җавап бирә.

Мәсәлән, Җире аз кешеләр батраклыкка яллана иделәр.

Иярчен вакыт җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең вакытын белдерә һәм кайчан? кайчаннан бирле? кайчанга чаклы? дигән сорауларга җавап бирә.

Мәсәлән, Алар тиз генә юлдан чыктылар, ул да түгел күк атлы кеше узып та китте.

Иярчен урын җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең вакытын белдерә һәм кайда? кайдан? кая? кебек сорауларга җавап бирә .

Мәсәлән, Балалар бакчалары булган җирдә хатын - кызлар җитештерүчән хезмәттә актив катнашалар .

Иярчен рәвеш җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең рәвешен белдерә һәм ничек? ни рәвешле? кебек сорауларга җавап бирә .

Мәсәлән , Мин аларны шулай итеп утыртырмын: бер - ике елдан эре – эре алмалар бирә башларлар .

Иярчен күләм җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең һәм билгенең күләмен белдерә һәм күпме ? никадәр ? ни дәрәҗәдә ? кебек сорауларга җавап бирә .

Мәсәлән , Без шәһәрдә сез торган кадәр булдык .

Иярчен сәбәп җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең сәбәбен белдерә һәм ник ? нилектән ? ни сәбәпле? нәрсә аркасында ? кебек сорауларга җавап бирә .

Мәсәлән , Монда эш кайный , шуңа күрә күңелле .

Иярчен максат җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең максатын белдерә һәм ни өчен ? ни максат белән ? дигән сорауларга җавап бирә .

Мәсәлән, Әти-әнисе аның хәлен белеп торсын дип, Марат аларга атна саен хат язды .

Иярчен шарт җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең үтәлү – үтәлмәвенә шарт булган эш яки хәлне белдерә һәм нишләсә? ни булса? нинди шартларда? дигән сорауларга җавап бирә .

Мәсәлән, Дөресен әйтик, юкса ул яратмас .

Иярчен кире җөмлә көтелгән эш яки хәлнең баш җәмләдә киресе булачагын белдерә    һәм нәрсә булса да? нәрсәгә карамастан? сорауларына җавап бирә .

Мәсәлән,  кайда гына барма, һәр җирдә бер үк җавап .